Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы



№6
Февраль 2018 г.

## День защитника Отечества




*Дорогие мужчины, мальчики!*

Разрешите поздравить Вас с праздником мужества, благородства и чести – С Днём защитника Отечества! И пожелать в этот день крепкого здоровья, неиссякаемой энергии, жизни, наполненной миром, счастьем и любовью близких! Уверенно шагайте к высотам успеха и процветания, всегда сохраняя оптимизм, бодрость и душевное равновесие!

*С уважением, редколлегия газеты!*

## Халыкара Туган тел көне

*И туган тел!*
*Сине Әнкә итеп*
*Йөрәгендә саклый бу халык.*
*Таралган ул...*
*Әгәр син булмасаң,*
*Бетәр иде күптән югалып.*
*Югалмадың,*
*Югалтмадың безне -*
*Халык исән калган син барга.*
*Бу дөньяга күзебезне ачтың,*
*Хакыбыз юк кабат йомарга.*

Һәр милләт, һәр халык өчен бәйрәм көн - Халыкара туган тел көне. Бу хәл Пакистанда 1952 нче елның 21 нче февралендә була. Бангл теленә дәүләт статусы бирүне таләп итеп чыгыш ясаган биш студент үтерелә. Шушы вакыйгадан соң 47 ел үткәч, 1999 нчы елда, 21 нче февраль Бангладеш тәкъдиме белән, ЮНЕСКО тарафыннан Халыкара туган тел көне дип игълан ителә.

Һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе- тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле. Бу - безнең балачагыбыз, гаиләбез, җәмгыятьтәге беренче тапкыр аралашуыбыз теле. Халыкара туган тел көнендә барлык телләр дә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга тиешбез.

Шул уңайдан мәктәптә бик күп чаралар узды. Алар турында 2, 3нче битләрдә укырсыз.



### Интересно знать!

- Рост Петра Первого составлял 213 см.
- Глаз страуса больше его мозга.
- Деньги не сделаны из бумаги, они сделаны из хлопка.
- Библия — самая продаваемая книга в мире.
- Город Рим есть на каждом континенте.
- У мотылька нет желудка.
- Арахис используется при производстве динамита.

### В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Татар телен ничәлегә беләсең? | 2 |
| Чит телне татар теле аша… | 3 |
| Республикакүләм конференция | 3 |
| Неделя русского языка и литературы | 4 |
| Неделя начальных классов | 4 |
| Алтын йөрәкле укытучыбыз | 5 |
| Фәнис Яруллинның тууына 80 ел | 5-6 |

# Татар телен ничәлегә беләсең?

**Яраткан шагыйрем Фәнис абый Яруллинның көндәлекләрен укыганым бар. 2010 елның, 28 нче апрелендә ул менәниләр язган:** *"Туган телеңне югалту — үз-үзеңне югалту ул. Рус, инглиз телендә генә сөйләшә башлыйсың икән, телисеңме-юкмы син аларның гореф-гадәтләрен, хәтта диннәрен дә кабул итәсең. Син алар җырын җырлыйсың, ләкин бит синең күңел төбеннән саркылып торган үз моңың бар. Син алар җырын да җиренә җиткереп җырлый алмыйсың, ата-бабаларыңнан саркып кергән моң да өскә калкып чыга алмый."*

беренче соравым рус милләтеннән булган сыйныфташым Степанов Данилга:

**-Данил, татар телен өй-рәнү сиңа нәрсә бирә?**

- Мин бит Татарстанда яшим. Аны өйрәнмичә мөмкин түгел. Аның бигрәк тә миңа татар хәрефләре кергән сүзләре ошый әле. Дусларым белән татарча сөйләшергә рәхәтрәк миңа.

Бу мәсьәләдә украин милләтле Софьяның үз фикере:

-Миңа башта авыр бирелде, тик мин чигенмәдем. Минемчә, татар теле иң матур телләрнең берседер. Әти белән әниемне дә татарча сөйләшергә өйрәттем әле мин.

**-Софья, татар теле дәресләрен кыскарту кирәк лыйсың?**

-Башта "2"ле иде, хәзер "4" ле дип уйлыйм.

**Софья:** Минеке "3" белән "4" арасында. Әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе миңа, Рүзәл.

Фатихов Рим аны "5"легә белә, чөнки төрки телләрнең кыпчак төркемено кергән казак теле – безгә тугандаш тел.

**-Мин татар телен бик яратам.** Миңа 7-8 яшь булганда, без Татарстанга күченеп кайттык. Телне белсәм дә, хәзер казак телендә бөтенләй сөйләшмим дисәң дә була. Әти-әнием, әби-бабайларым да бу телне су урынына эчә, - ди ул.



21 нче февраль –Халыкара туган тел көне, һәрберебез өчен бәйрәм көн. Бу көндә барлык телләр дә тигез дип таныла, чөнки аларның һәркайсы кеше язмышы өчен җавап бирә, һәркайсы табигый мирас булып тора һәм без аны, һичшиксез, сакларга тиешбез.

Безнең мәктәптә сигез төрле милләт баласы белем ала икән. Татар, рус, әрмән, украин, таджик, казах, үзбәк, азәрбайҗан дисеңме... Шунысы кызык: алар барысы да татар телен яратып йөрәнә. Мин алар белән шул хакта сөйләшеп алырга булдым. Иң

Хәзер әти-әнием, яшьтәшләрем һәм туганнарым белән рәхәтләнеп татарча сөйләшәбез.

Кавказ артыннан кайткан Азәрбайҗан кызы Карина:

-Андагы һәм мондагы телләрне чагыштырып карасаң, Рүзәл!.. Татар телен өйрәнә башлагач, мин бу телдә дусларым белән аралаша алырмын дип уйламаган да идем. Хәзер әлеге сүзләрем үземә дә көлке тоела. Татарстанда яшәгәч, татарча аралашу миңа рәхәт.

**-Карина, татар телен нинди билгегә беләм дип уй-иде дип уйлыйсызмы?**

-Ничек әйтергә? Аның урынына керә башлаган рус теле дәресләреннән мин кайчак арып та китәм. Татар теле бетә күрмәсен, дип борчылам. Барлык милләт кешесе үз телендә сөйләшергә, тарихын үз ана телендә өйрәнергә тиештер дип уйлыйм.

Әйе, һәркем өчен дөньядагы барлык телләр арасында иң кадерлесе - тәүге кабат сөйләшә башлаган ана теле.

Дустым, ә син татар телен ничәлегә беләсең?

**Рүзәл ШӘРИПОВ**, 8Б сыйныфы

# Чит телне татар теле аша...



***Бүгенге көндә чит телләр өйрәнү - замана таләбе. Тел - кешеләргә бер-берсе белән аралашырга, фикер алышырга һәм үзара аралашуга ярдәм итә торган иң мөһим чара. Шуңа күрә чит телләрне укытуның иң нәтиҗәле методларын эзләү, иҗади эшләү безнең төп бурычыбыз булып тора.***

Чит телләрне ана теленә нигезләнеп укытып та нәтиҗәгә ирешеп була. Бигрәк тә бу башлангыч сыйныф укучыларына кагыла. Ә ана телендә таныш булмаган сүзләрнең тәрҗемәсен биреп бару, биремнәрне аңлату балага чит телне ана теле белән чагыштырып барырга мөмкинлек тудыра. Бу грамматик, лексик һәм фонетик яктан да зур әһәмияткә ия.

Инглиз теленең фонетик төзелеше бик үзенчәлекле. Татарлар өчен инглиз телен өйрәнү интонацион яктан да, авазлар системасы ягыннан да бик катлаулы. Чөнки инглиз телендә сүз эчендә авазлар һәм хәрефләр арасында шактый зур аерма бар. Алфавитның 26 хәрефе 44 сузык һәм тартык фонеманы белдерә. Бу инглиз телен өйрәнүдә иң катлаулы якларның берсе.

Инглиз һәм татар телләренең фонетик системасында уртак яклары күп. Мәсәлән, инглиз телендәге [h], [ә], [w], [з], [эе] авазларын рус теле аша түгел, нәкъ менә татар теле аша биреп бару күпкә җиңелрәк. Чөнки бу авазлар татар телендә дә бар: [h, ө, в, ж, ә].

Билгеле, чит тел дәресендә ана теле ярдәмче вазыйфасын гына үти. Дәресне тулысынча диярлек ана телендә алып бару зур хата булыр иде. Шуны истән чыгармаска кирәк, кечкенә балаларның төп эшчәнлеге - уен. Шуңа күрә чит тел өйрәнгәндә дә, балаларда кызыксыну уяту өчен, уен формасын куллану бик мөһим. Ләкин бу инглиз теле белән бергә үрелеп барырга тиеш.

Татарча әйтелгән һәр фразаны шунда ук, кычкырып һәм ачык итеп, инглизчә кабатларга кирәк. Укытучының төп бурычы - ана телен мөмкин кадәр аз кулланып, чит телдә уеннарны аңлатуга ирешү. Монда инде төрле рәсем-картиналар, ишарә, хәрәкәт һәм мимикалар да эшкә җигелә.

Ана теле аша чит телне өйрәнүгә тагын бик күп мисаллар китереп булыр иде. Безгә бары тик эзләнергә, иҗади яктан үсәргә һәм балаларны яратырга кирәк.

**Рәсимә ИБРАЕВА**,
татар теле укытучысы

**Миләүшә ХӘЙРУЛЛИНА**,
инглиз теле укытучысы

# Республикакүләм конференция



16 февральдә КФУның татар журналистикасы кафедрасы: "Журналистикада заманча мәгълүмати технологияләрне тормышка ашыруда татар теленең роле" темасына фәнни-гамәли конференция үткәрде. Безнең мәктәптән 9нчы сыйныф укучылары Зәбирова Зөләйха(укытучысы Ибраева Р.Х.), Заһриева Ильвина (укытучысы Зәбирова Э.Ш.), татар теле укытучысы Р.Х. Ибраева Диплом белән бүләкләнде. Иң яхшы мәкаләләр буларак хезмәтләре җыентыкта урын алды. Җиңүчеләргә уңышлар телибез!

# Неделя русского языка и литературы




***16 февраля в школе была проведена литературно-музыкальная композиция «По страницам великой жизни». Под руководством учителей русского языка и литературы Малафеевской А.В., Хабреевой Р.Б., Ибрагимовой Г.Г. Ребята подготовили насыщенную программу о жизни и творчестве Толстого Л.Н.***

Ученики 11-х классов – Зайнуллина Чачка, Салимзянов Ильгиз, Хабреева Алия, Хасанова Алсу провели заочную экскурсию по Ясной Поляне, месту, где родился писатель и где он провёл большую часть своей жизни, черпал обильный материал для своего творчества. Рассказы о жизни писателя чередовались с чтением стихотворений, посвящённых Л .Н. Толстому.

В актовом зале школы звучала музыка композиторов, чьё творчество особенно почитал Л .Н. Толстой. Ученики 6 б класса рассказали о его педагогической деятельности. Толстой сам обучал ребят грамоте. В 1870-х годах он создал «Азбуку» и первоначальные книги для чтения.

Никого из присутствующих не оставила равнодушным виртуальная экскурсия по литературным местам г. Казани, связанных с именем писателя.

Как известно, прадед писателя был воеводой Свияжска. А дед Илья Андреевич дослужился до губернатора Казани. Так что не удивительно, что именно сюда из Ясной Поляны осиротевший 13-летний Лев Толстой вместе с братьями перебрался в 1841 году.

К слову, при поступлении Толстому еще не исполнилось 16 лет, но для него сделали исключение. Вообще молодой граф вел в Казани веселый образ жизни: балы, концерты, театры. Этакий светский львенок. Но параллельно он много читал о «главнейших вопросах нашего бытия». Казанский период оставил серьезный след в его творчестве, например, в произведениях «После бала», «Утро помещика», трилогии «Детство», «Отрочество», «Юность».

Соприкоснувшись с жизнью и творчеством великого писателя, ребята старались понять своеобразие личности Л.Н. Толстого — человека высочайшей нравственности, самоотверженного служения людям.

**Рафига *ХАБРЕЕВА*,**
учитель русского языка и литературы

# Неделя начальных классов

***С 29 января по 3 февраля в нашей школе прошла неделя начальных классов.***

Фарида Гафарова провела открытый урок в 4а классе по русскому языку на тему "Несклоняемые имена существительные" и подготовила викторину по сказкам Г.Х.Андерсена.




Клара Галиуллина дала открытый урок по окружающему миру в 1а классе на тему "Домашние и дикие животные".

Венера Мухутдинова ознакомила 1б класс с буквой “Ш”.

Во 2-х классах прошло внеклассное мероприятие "Будущие переводчики". Провели его Наталья Абызова и Алсу Хисамиева.

Айгуль Сабирзянова дала открытый урок в 4б классе на тему "Сложение и вычитание величин".

Ралина Саляхова провела урок математики в 1в классе на тему "Закрепление знаний таблиц сложения и вычитания".

Халкыбызның киләчәге – укытучының алтын йөрәгендә

*А.Фадеев*

# *Алтын йөрәкле укытучыбыз*

***Мәктәптә һәркемнең күңел түренә кереп калган укытучысы, тәрбиячесе була. Бездә андый укытучылар күп.***

Безне рус теле һәм әдәбияты укытучысы Сәлахова Альбина Абдулловна инде 5 нче сыйныфтан бирле укыта. Ул шулкадәр мавыктыргыч итеп сөйли белә, аның сөйләгәнен сәгатьләр буе авызыңны ачып тыңлап торасың.

Укытучыбызны тормыш төрле яклап сыный, шулай да ул авырлыклар алдында баш имичә, тормыш сынауларына бирешмичә, алга баруын дәвам итә.

Сине аңлардай, сине яратырдай, сиңа шәхес итеп карардай, син шатланганда шатланып, син кайгырганда кайгырырдай кешең булу укучы өчен нинди зур бәхет! Минемчә, укытучы белән укучы арасында нindидер бөтенлек бар. Безнең арада да бар кебек ул. Без дәресне шатланып каршы алабыз. Авырып китсә дә, башкалар кебек “буш дәрес” дип сөенмибез. Ул бит без белсен, теманы аңласын, һәр яктан камил, укымышлы, тәрбияле, эстетик зәвыклы кеше булып үссен өчен күп көч куя. Кечкенә генә уңышыбызны да күреп ала, аны тагын да үстерергә ярдәм итә.



Дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышларыбызның башында укытучы торганын һәркем таный. Әйе, нәкъ менә алар безне мәгърифәт дөньясына алып керә, хәреф танырга, язарга өйрәтә, белгәннәрен хәтеребезгә сеңдерергә тырыша, шуларны үзебездән таләп итә, тәрбияле булырга өнди.

Кемдер укытучысын кырыс, әмма гадел булганы өчен, кемдер шәфкатьле яки таләпчәнлеге өчен якын күрә. Мәктәп еллары артта калгач, укытучының шундый гадәте бар иде, дип тә сагынып һәм яратып искә аласыңдыр әле ул.

Дуслар, әйдәгез язык әле укытучыларыбыз хакында. Мактыйк әле үзләрен. Алар моңа лаек бит. Язмаларыгызны “Алтын йөрәкле укытучыбыз” рубрикасында көтеп калабыз.

**8Б сыйныфы укучылары**

# Фәнис Яруллинның тууына 80 ел

***Күренекле балалар шагыйре Фәнис Яруллин 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районында колхозчы гаиләсендә туа.*** 4 яшь чагында әтисе Гатаулла абзыйны фронтка озаталар һәм, күп тә үтми, аның сугыш кырында ятып калуы турында үлем хәбәре килә.

Жидееллык белемне туган авылында ала, сигезенче сыйныфны Баулы урта мәктәбендә тәмамлый.



«Татнефть» берләшмәсенең Баулы элемтә конторасында монтер булып эшли башлый. 1957 елда Совет Армиясе сафларына чакырыла. Армиядә һава укчы радистлар мәктәбендә укый, спорт белән мавыга. Спорт күнегүләренең берсендә турниктан егылып, имгәнеп, гомерлеккә йөри алмас хәлдә кала.

Озак еллар урын өстендә яки хастаханәләрдә дәваланып ятуына карамастан, ул бөтен тырышлыгын, рухи көчен үзенең белем дәрәҗәсен күтәрүгә, әдәби иҗат эшенең серләрен үзләштерүгә юнәлтә..

*(Дәвамы 6 нчы биттә...)*

# Фәнис Яруллинның тууына 80 ел

*(Ахыры. Башы 5нче биттә)*

...1963 елда урта мәктәп программасы буенча экстерн тәртибендә имтихан тота, 1970 елда исә читтән торып укып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Шул елларда илһамланып шигырьләр, хикәяләр яза.

Аның беренче иҗат тәҗрибәләре матбугатта 1960 елда Баулы район газетасында, аннан соң республика газета-журналларында басылалар. 1964 елда Ф.Яруллинның беренче мөстәкыйль китабы – «Мин тормышны яратам» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Шулардан «Аерылмас дустым» һәм «Сулыш» шигъри җыентыклары өчен автор М.Җәлил премиясенә, ә лирик шигырьләре һәм поэмалары тупланган «Җан авазы» исемле китабы өчен 1995 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Әдипнең иҗат мирасында Татарстан һәм Башкортстан театрларында куелган дистәдән артык сәхнә әсәрләре дә бар. Язучы 1985 елдан «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем йөртә, Халыклар Дуслыгы ордены кавалеры. Татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен Фәнис Яруллинга 2001 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәйми-евнең Указы белән «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән исем бирелә. Кызганыч, язучы 2011 елның 8 декабрендә безнең арабыздан мәңгелеккә китеп барды.

Ул 80 яшьлек юбилеен билгеләп үткән булыр иде. Шул уңайдан безнең мәктәптә шагыйрь иҗатына багышланган әдәби кичә булып узды. Анда Фәнис Яруллинның туганы Халидә Халитова катнашты. Ул язучының тормышы турында сөйләде. Кичәдә ветеран укытучы Мөслимә Низамова, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, 10нчы сыйныф укучылары, аларның сыйныф җитәкчесе чыгыш ясады.

**Фаил КӘРИМОВ,**
8Б сыйныфы



Отправляйте интересующие вас вопросы на наш электронный адрес schoolschool2017@bk.ru. На них попытается ответить администрация школы. Ответы на них вы сможете увидеть уже в следующем номере газеты!


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Ответственный секретарь*** Рузаль Шарипов
***Фотокорреспондент*** Диана Галимова
***Редколлегия*** Алия Хабирова
Гузель Насибуллина
Инсаф Насибуллин
Фаиль Каримов

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2